ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11. 03. 2021 г. № 50

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2014 елның 26 мартындагы 45 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Түбән Кама шәһәре Уставының 51 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2015 елның 1 декабрендәге 480 номерлы «Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2014 елның 26 мартындагы 45 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.3. пунктында «Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесе» сүзләрен «Түбән Кама шәһәренең Бердәм заказчысы дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

1.3.1. пунктында:

«Түбән Кама шәһәренең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесе» сүзләрен «Түбән Кама шәһәренең Бердәм заказчысы дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

«301 каб.» сүзләрен «201 каб.» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.6. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Авария ситуациясен бетерү белән бәйле җир эшләре башкарылган очракта, дүртенче абзацта күрсәтелгән мәгълүмат соратып алынмый.».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Р. Салаватов

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881